**АКШ ПРЕЗИДЕНТЫ ТРАМПНЫҢ БАБАСЫ – ТАТАР?** 2

**ИРЛЕК БУРЫЧЫН ҮТӘМӘСӘҢ – ШТРАФ?** 5

**ЭЧКЕЧЕЛЕК БЕЛӘН КӨРӘШӘ БАШЛЫЙБЫЗ!** 6


# Сиражи СҮЗе

16+

№12(30) ДЕКАБРЬ 2016 ЕЛ




ТӨРЛЕ ЯКТАН КАРАШ

## МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

### КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!



Газета-журналларга язылу кампаниясе бетүен бераз шүрләбрәк көтеп алам – тагын нинди сюрпризлар әзерләрләр икән инде? Югыйсә, узган ел язылуны 15 декабрьдән үк ябып куйдылар да, соңгы көннәргә кадәр сузып йөрүчеләр өлгерми калды. Менә быел да 15нче декабрьдә ябулары бар, диләр. Шуңа күрә, газетабыз дусларына мөрәҗәгать итәм: иртәрәк язылып калыгыз. Югыйсә, былтыр да беренче санны эзләп редакциягә шалтыратучылар күп булды. Ә ул иң кызыклы саннарның берсе – «Татар җыры» фестиваленә бәя бирелә, бөтен артистлар энәсеннән-җебенә тикле тикшерелә... Кыскасы, шәп сан! Гомумән, газетабыз шәп! Чөнки ул сезнең өчен языла, ә без үз укучыларыбызны бик ярата-быз!

*Ихтирам белән,*
*Искәндәр СИРАҖИ.*






**БАШКАЛА БАЗАРЫНДА ИТ БӘЯЛӘРЕ...** 27



**РАДИК ЮЛЬЯКШИН ГАУГА ЧЫГАРДЫ!** 10



**ПАЙ ҖИРЕН НИЧЕК АЛАСЫ?** 34

*«СИРАҖИ СҮЗе» газетасына киләсе яртыеллыкка язылу дәвам итә. Язылу индексы – 16021. Алты айга язылу бәясе – 308 сум.*

## БУ САНДА:


Мамадыш имамы һәм ришвәт турында... 20

Салават Миңнехановтан тракторист чыгамы? 24

Татар бизәкле күлмәкләр модасы керде... 25

Буада кеше гомере – нибары 900 сум!? 28

Балтач укытучылары тагын зарлана... 30

Русиянең иң карак түрәләре кемнәр? 35

Рамзан Кадыйров өч көндә хәмерне бетерде! 36

Казанның сәер һәйкәлләре кайда тора? 40



# КУРАЙ – ТАТАРНЫКЫ ТҮГЕЛ?

**Без курайны «татар-башкорт музыкаль инструменты» дип уйларга күнексәк тә, Татарстанда аны безнеке дип санамыйлар икән. Башкортлар үз курайлары өчен җан атып торалар, ә безнең республикада ул милли уен кораллары исемлегенә дә кермәгән. Музыка мәктәпләрендә дә балаларны курайда уйнарга өйрәтү буенча рәсми укыту планнары да юк. Ә бит гаҗәеп матур һәм серле курай көйләрен һәрвакыт мөкиббән китеп тыңлыйбыз...**

Курай кайсы милләтнеке соң? Бу сорау Казандагы 32 нче санлы татар балалар музыка мәктәбенең курай бүлеге укытучысы **Рафаэль** абый **Гайзетдинов**ны да борчый икән. Инде җитмешне куып килгән Рафаэль Гайнетдин улы, һөнәре буенча баянчы булса да, курайны үз иткән. Алты ел элек ул курайны үзе үк ясый башлый.

Борынгы Болгарда һәр елның май аенда халкыбыз Ислам динен кабул иткән көн билгеләп үтелә. Анда Рафаэль абый да ел саен катнаша торган була. Ләкин өч ел элек аны бәйрәмгә алып бармый башлыйлар. Баксаң, Татарстан Мәдәният министрлыгында моны, курай татар милли музыкаль инструментлары исемлегенә кермәгән, дип аңлаталар икән. Ә аңарчы ул татарныкы булганмы?

Шуннан соң Рафаэль абый, үз-үзенә: «Нүжәли мин татарныкы булмаган курай ясап ятам?» – дигән сорау бирә. Моннан соң ул, төрле белгечләргә мөрәҗәгать итеп, шушы мәсьәләгә ачыклык кертергә тели. Аларның берсе дә курайның килеп чыгуы турында төгәл генә мәгълүмат бирә алмый. Җырчы Рөстәм Маликов бу курайларны, гомумән, күрә алмый икән. Ул Рафаэль абыйга: «Бу татар курае түгел. Татарның курае юк. Ясама да, рекламалама да», – дигән «киңәш» биргән.

Үзе ясаган инструментларны күргәзмәләргә дә йөртә Рафаэль Гайзетдинов. Анда да, башкортлар килеп: «Татарның курае булмаган аның», – дип әйтә торган була. Бу сүзләргә курайчының җаны әрни. Шуннан соң ул инструментларга лазерлы гравировка белән «Татар курае» дип яздыра башлый. Аның янына, гарәпчә, «Рафаэль» дип тә өстәп куя. Бу курайларны, үзенә күрә, «бренд»лы, дип тә әйтеп була хәзер.

Рафаэль Гайнетдин улы Казан читендә үз йорты белән яши. Аның курай ясау өчен зур остаханәсе бар. Анда 14ләп станок исәпләнә. Курайлар, нигездә, алюминнән ясала. Чөнки шпоннан ясалганнары кыска гомерле була – тиз ватыла. Башта көмеш төсендә булган алюмин курайларны Рафаэль абый соңрак агач төсенә буйый башлый. Болай алар зәвыклырак күренә. Ул барлыгы 17 төрле озын һәм кыска курай ясый. Бу курайлар башкортныкыннан тишек саннары белән генә түгел, мундштуклы булулары белән дә аерылып тора. Мундштук булгач, уйнарга өйрәнү җиңелрәк. Ә балалар нәкъ менә өйрәнергә җиңелрәк булган музыкаль инструментны сайлый. Бүгенге көндә Рафаэль абыйның классында 26 бала шөгыльләнә. Алар төрле конкурсларда катнаша. Әле интервью алырга баргач та: «Кичә Мәдәният университетында узган «Этномириада» конкурсында беренче дәрәҗә лауреат булып кайттык», – дип, сөенечен уртаклашты курайчы.

Рафаэль абый курайларны Универсиада һәм Су спорты төрләре буенча Дөнья чемпионатында да тәкъдим иткән булган. Аларны 45 илдән 250ләп музыкант сатып алган, Русиянең күп кенә төбәкләреннән килгән кешеләр алып киткән... Ашхабадта узган Татарстан көннәренә дә алып бара ул курайларын. Төрекмәнстанда да ул ясаган курайлар бар. Төрекмәннәрдә исә курай милли инструмент булып санала икән. Алар аны күз карасы кебек саклыйлар...

Курай кемнеке соң? Бу сорауны курай буенча диссертация авторы, сәнгать фәннәре кандидаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе **Геннадий Макаров**ка бирдем: «Курай үзе – үсемлек исеме. Ул урманда үсә. Курай инструментының милләте юк, шуңа күрә, аны теләсә кайсы халык үзенеке дип әйтә ала. Татарстан урманнарында да курай үсә. Шуңа күрә курайны татарныкы, дип санарга безнең тулы хакыбыз бар. Милли инструментлар исемлеген кем төзегәнен мин белмим. Аны музыка буенча фәнни эзләнүләр алып барган кеше төзесә, яхшырак булыр иде. Курайны, һичшиксез, татар милли инструменты исемлегенә кертергә кирәк», – диде Геннадий Михайлович.

**P.S.** Курай проблемасы глобаль түгел, билгеле. Әмма безнең республикада милли традицияләргә, татар мәдәниятен үстерүгә ниндирәк караш икәнен шушыннан да чамалап була. Бер сөйләшкәч, әллә нәрсәләр килеп чыга бит ул. Менә Рафаэль Гайзетдинов белән очрашкач та, үземә тагын бер кызыклы мәгълүмат алдым. Безнең Казанда элегрәк музыкаль инструментлар фабрикасы булган икән. Анда фортепианолар, кубызлар, баяннар һәм башка музыка уен кораллары ясаганнар. Ләкин дәүләт бу фабриканы финаслауны кирәк дип тапмаган һәм аны япканнар. Бу фабрика бинасында хәзер табутлар (гроблар) ясыйлар, ди. Шул ук Башкортстанда хәзерге вакытта музыка кораллары ясаучы ике фабрика эшләп килә. Кирәк дип тапкач, булдыралар. Ә безгә музыка кирәк түгелдер инде алайса?!.

*Ләйсән САБИРОВА.*